ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**БОЕРЫК**

29.04.2021 № 77-од

Казан шәһәре

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының 2017 елның 24 октябрендәге 134-од номерлы боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенең һәм Татарстан Республикасы муниципаль архивларының комплектлау чыганаклары булган оешмаларының эш башкару буенча инструкциясен, эшләрнең якынча яки индивидуаль номенклатурасын, архив турындагы нигезләмәсен, үзәк эксперт комиссиясе яисә даими эшләүче эксперт комиссиясе турындагы нигезләмәсен килештерү буенча Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында
.

Норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының 2017 елның 24 октябрендәге 134-од номерлы боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенең һәм Татарстан Республикасы муниципаль архивларының комплектлау чыганаклары булган оешмаларының эш башкару буенча инструкциясен, эшләрнең якынча яки индивидуаль номенклатурасын, архив турындагы нигезләмәсен, үзәк эксперт комиссиясе яисә даими эшләүче эксперт комиссиясе турындагы нигезләмәсен килештерү буенча Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының 2018 елның 26 ноябрендәге 183-од номерлы, 2020 елның 5 августындагы 155-од номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) кертелә торган кушымта итеп бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Рәис Г. З. Габдрахманова

Татарстан Республикасының
Архив эше буенча дәүләт
комитетының 2021 елның
29 апрелендәге 77-од
номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының 2017 елның 24 октябрендәге 134-од номерлы боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенең һәм Татарстан Республикасы муниципаль архивларының комплектлау чыганаклары булган оешмаларының эш башкару буенча инструкциясен, эшләрнең якынча яки индивидуаль номенклатурасын, архив турындагы нигезләмәсен, үзәк эксперт комиссиясе яисә даими эшләүче эксперт комиссиясе турындагы нигезләмәсен килештерү буенча Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2.14 пунктында:

«Стандартка карата куелган таләпләрнең эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү Дәүләт комитеты бинасында һәм аның янгынга каршы тору системасы һәм янгын сүндерү системасы белән, һава кондиционерлау системасы, документларны тутыру өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бүлмәләрендә алып барыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиалы мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

Инвалидларның, шул исәптән кресло-коляскалардан һәм сукырларны йөртә торган этләрдән файдаланучы инвалидларның, бинага, бүлмәләргә керә һәм хезмәтләрдән файдалана алуы өчен шартларны тәэмин итү чаралары күрелә, шул исәптән:

бинага һәм бүлмәләргә тоткарлыксыз керә алу, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыкларсыз файдалана алу өчен шартлар;

ял итү урыннарына тоткарлыксыз керә алу һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыкларсыз файдалана алу өчен шартлар;

автомобиль транспортыннан һәм шәһәр, шәһәр яны, шәһәрара элемтәдә шәһәр җир өсте электр транспортыннан, элемтә һәм мәгълүмат чараларыннан (светофорларның ут сигналларын һәм транспорт коммуникацияләре аша җәяүлеләр хәрәкәтен җайга сала торган җайланмаларны тавыш сигналлары белән кабатлауны тәэмин итүче чараларны да кертеп) тоткарлыксыз файдалану өчен шартлар;

бинага һәм бүлмәләргә тоткарлыксыз керә алу, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыкларсыз файдалана алу өчен шартлар;

Дәүләт комитеты территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, Дәүләт комитеты бинасына мөстәкыйль керү һәм чыгу, транспорт чарасына мөстәкыйль утыру һәм аннан төшү, шул исәптән кресло-коляска кулланып, мөмкинлеге;

күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе нык бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;

инвалидларның бинага, бүлмәләргә тоткарлыксыз керә алуын һәм хезмәтләр күрсәтүдән каршылыкларсыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат чыганакларын аларның яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып урнаштыру;

инвалидларга кирәкле тавышлы һәм карый торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-нокталы Брайль шрифты белән ясалган билгеләр ярдәмендә кабатлау, сурдотәрҗемәчедән һәм тифлосурдотәрҗемәчедән файдалана алу;

озатып йөрүче этнең, аның Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Озатып йөрүче этнең махсус өйрәтелүен дәлилли торган документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган форма буенча һәм тәртиптә өйрәтелүен дәлилли торган документы булганда, бинага һәм бүлмәләргә керә алуы;

хезмәтләр күрсәтүче хезмәткәрләрнең инвалидларга аларның башка затлар белән беррәттән хезмәтләр күрсәтүдән файдалануына комачаулый торган башка киртәләрне җиңәргә ярдәм күрсәтүе»;

«Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 181-ФЗ номерлы Федераль закон);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба – ТР Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары)»;

2.15 пунктында:

«Стандартка карата куелган таләпләрнең эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән һәркемнең файдалана алуы күрсәткечләренә түбәндәгеләр керә:

Дәүләт комитеты биналарының җәмәгать транспортына якын булу зонасында урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү башкарыла торган бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Дәүләт комитетының рәсми сайтында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүматның булуы;

Дәүләт комитеты бинасының һәм бүлмәләренең инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга тоткарлыксыз керә алуын булдыра торган чаралар һәм җайланмалар белән тәэмин ителүе, шулай ук инвалидларга дәүләт хезмәтен күрсәтүне тәэмин итә торган башка шартларның үтәлүе;

инвалидларның бүлмәләргә керә алуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәтләр күрсәтелүгә комачаулый торган башка киртәләрне җиңеп чыгуда инвалидларга ярдәм күрсәтү.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләренә түбәндәгеләр керә:

документларны кабул итү һәм карау сроклары үтәлү;

дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен алу срогы үтәлү;

Дәүләт комитеты белгечләре тарафыннан әлеге Регламент бозылуга дәлилләнгән шикаятьләрнең булмавы;

Дәүләт комитеты белгечләренең мөрәҗәгать итүче белән аралашуы саны:

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны турыдан-туры тапшырганда - иң күбе бер тапкыр (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә - иң күбе бер тапкыр (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

Дәүләт комитеты бинасына, дәүләт хезмәте күрсәтү бүлмәләренә инвалидларның керә алуы.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза биргәндә һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен алганда, дәүләт хезмәтен күрсәтүче вазыйфаи затның һәм мөрәҗәгать итүченең бер тапкыр аралашуы күздә тотыла. Аралашу дәвамлылыгы Регламентта билгеләнә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, дәүләт хезмәтен күрсәтү күпфункцияле үзәк аша, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннарында башкарылмый.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында мәгълүматны мөрәҗәгать итүче Дәүләт комитетының http://www karhiv.tatarstan.ru сайтында, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында алырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында күрсәтелми.»;

«Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«181-ФЗ номерлы Федераль закон;

ТР Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары;

бишенче бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт комитеты, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирүнең судка кадәрге (судтан тыш) тәртибе»;

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шикаять ул кергән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карау срогы - аны теркәгән көннән алып унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган вазыйфаи затының мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән йә җибәрелгән төгәлсезлекләрне һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгән очракта яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылуга шикаять белдерелгән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.».